**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында2021 елда экономияләнгән гражданнарның үзара салым акчаларын 2022 елда файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

**27 нче ноябрь 2021 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2021 елда Сәпәй авыл җирлегендә контейнер мәйданчыклары (контейнерлар, коймалар өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез корылышы, коймалар) урнаштырганнан соң янга калган (экономияләнгән) 13 885 (унөч мең сигез йөз сиксән биш сум 69 тиен) сум гражданнарның үзара салым акчасын 2022 елда

- Сәпәй авыл җирлегендә җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территорияләрен) чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре, территорияне яшелләндерү буенча чаралар уздыру өчен файдаланырга.

2. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Галиева